ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю станциясепоселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **К А Р А Р**

___ _23.10.2025_______ № 779_

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2025 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» муниципаль программасын раслау турында» 2024 елның 23 сентябрендәге 878 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру, Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының «2024-2025 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Карарның исемендә «2024-2025» саннарын «2025-2026» саннарына алмаштырырга.

1.2. 1 пунктта «2024-2025» саннарын «2025-2026» саннарына алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары белән расланган «2024-2025 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» муниципаль программасына (1 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.1. Карарның исемендә «2024-2025» саннарын «2025-2026» саннарына алмаштырырга.

2.2. Программа паспортын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Наименование Программы | «2025-2026 елларга Биектау муниципаль районы территориясендә яшь белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү» муниципаль программасы (алга таба – Программа) |
| Программаның заказчысы | Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты |
| Программаның | Биектау муниципаль районы территориясендә яшь |

<table>
<tr><td>максаты</td><td colspan="2">белгечләрне җәлеп итү һәм беркетү<br>Мәгариф системасының гомуми белем бирү учреждениеләре яшь белгечләренә социаль-икътисадый ярдәм</td></tr>
<tr><td>Программаның бурычлары</td><td colspan="2">Педагогик кадрларга булган ихтыяҗны тулысынча тәэмин итү өчен социаль-икътисадый ярдәм системасын булдыру. Муниципаль мәгариф учреждениеләрендә яшь белгечләрне беркетү һәм санын арттыру. Мәгариф системасында эшләүче яшь белгечләрнең тормыш дәрәҗәсен күтәрү.</td></tr>
<tr><td>Программаны тормышка ашыру сроклары</td><td colspan="2">2025 - 2026 еллар</td></tr>
<tr><td>Финанслау күләмнәре һәм чыганаклары</td><td colspan="2">Программаны финанслауның гомуми күләме муниципаль бюджет акчалары 5 500 000 сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:<br>2025 – 2 500 000 сум.<br>2026 – 3 000 000 сум.</td></tr>
<tr><td>Программаны башкаручылар</td><td colspan="2">«Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты мәгариф бүлеге» МКУ</td></tr>
<tr><td>Программаны гамәлгә ашыруны контрольдә тоту</td><td colspan="2">Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты</td></tr>
<tr><td rowspan="3">Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеге индикаторлары һәм бәяләү</td><td>Программа максатларының индикаторлары аталышы</td><td>Программаны гамәлгә ашыру тәмамланганнан соң программаның максатына ирешү индикаторлары күрсәткечләре</td></tr>
<tr><td rowspan="2">Яшь белгечләрне җәлеп итү</td><td>2025 ел – 25 кеше</td></tr>
<tr><td>2026 ел – 30 кеше</td></tr>
</table>

2.3. «Программаны финанс белән тәэмин итү» III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III.«Программаны финанс белән тәэмин итү»

Программаны финанслауның гомуми күләме муниципаль бюджет акчаларыннан яшь белгечләргә бер тапкыр түләнә торган түләүгә 5 500 000 сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча:

2025 – 2500 000 сум.

2026 – 3 000 000 сум.»

2.4. «Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган файда» V бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«V. «Программаны гамәлгә ашырудан көтелә торган файда»

Программаны гамәлгә ашыру 2025 елда түбәндәге күрсәткечләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк:

1. Мәгариф учреждениеләрен педагогик кадрлар белән тәэмин итәргә;

2. Мәгариф учреждениеләрендә яшь белгечләрнең санын арттырырга;
Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә түбәндәге күрсәткечләргә ирешеләчәк:

| Көтелгән нәтиҗә | 2025 ел | 2026 ел |
|---|---|---|
| "Мәгариф" тармагында яшь белгечләр саны | 25 | 30 |

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү өчен Программа чараларын үтәүне чагылдыра торган максатчан индикаторлар кулланыла.

Программаны гамәлгә ашыруның нәтиҗәлелеген бәяләү тиешле ел эчендә ирешелгән күрсәткечләрне расланган күрсәткечләр белән чагыштыру юлы белән башкарыла.»

2.5. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф системасы гомуми белем бирү учреждениеләре яшь белгечләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибе» 2 кушымтасының 3 бүлегендәге 3.1 пунктта «2024-2025» саннарын «2025-2026» саннарына алмаштырырга.

3. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф системасы гомуми белем учреждениеләре яшь белгечләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турындагы документларны карау муниципаль комиссиясе составына (3 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.1. Шәйдуллин Дамир Фәрит улын чыгарырга, Хәкимуллин Рамил Фатыйх улын – Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен, аны комиссия рәисе итеп билгеләп кертергә.

4. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 августындагы 878 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы мәгариф системасы гомуми белем бирү учреждениеләре яшь белгечләренә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү бирү турындагы документларны карау буенча муниципаль комиссия эше турындагы нигезләмәгә (4 нче кушымта) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1. 1.2 пунктта «2024-2025» саннарын «2025-2026» саннарына алмаштырырга.

5. Карарны интернет челтәрендә «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча игълан итәргә.

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары – мәгариф бүлеге башлыгы И.Ә. Халитовка йөкләргә.

Җитәкче Р.Ф. Хәкимуллин